# Иж-бубый авыл китапханэсе.

Китапханә авыл советы карары белән 1952 елның 1августында ачыла. Аңа кадәр клуб каршында 2411 данә китап һәм брошюралары булган уку йорты (изба читальная) эшләгән. Китапханәне ачып, оештырып җибәрүче Шакирова Илсөяр булган.Ул 1952-1954 елларда эшләгән. Ул эшләгән елларда китапханә авыл халкын тәрбияләү йөзеннән конференцияләр, тематик һәм әдәби чаралар үткәрелә торган булган. Китапханәнең бу эшләрендә Иж - Бубый урта мәктәбе укучылары, аеруча мәктәп директоры Аминова Зәкия Мәхмүт кызы ярдәм иткәннәр.

Китапханәдә 1954 нче елдан башлап Ахмадишина Фәйрүзә Шигәбетдин кызы эшли башлый. Китапханәнең китап фонды һәм китап укучылар составы елдан - ел арта бара.

1968 елдан барлык укучылар 641 булып,159-колхозчы,12-эшче,108-хезмәткәр, 318-мәктәп укучысы файдаланган. Китапны пропаган-далау һәм яңа укучылар тарту өчен китапханәдә төрле

чаралар:әңгәмә, обзор, күргәзмәләр ясап, кичәләр үткәргәннәр. Бу эшләргә ярдәмгә, китапханә активы, авыл советы депутатлары,укы-тучылар,специалистлар һәм мәктәп укучылары ярдәмгә килгән.

Ахмадишина Фәйрүзә Шигәбетдин кызыннан соң Муратова Асия апа эшен дәвам итә.

1985-1996 елга кадәр авыл китапханәсендә Асия апа эшли. Балалар-ны бик ярата. Алар белән курчак театрлары оештыра. Мәсәлән, үземнең истә калган әсәре:А.Алишның “Сертотмас үрдәк”экиятен сәхнәләштерә. Балалар әкиятне бик яратып кабул итәләр.Асия апа балаларны бик ярата,үзенең дә өч кызы бар. Алар да китапханәгә йөрүләрен дәвам итәләр. Бүгенге көндә оныклары китапханәгә йөрүләрен дәвам итәләр.

1996 - 2000 елларда китапханәдә Ахметзянова Гөлнур Рәис кызы эшли.Укучылар белән төрле кичәләр, викториналар, конкурслар, кычкырып укулар оештыра. Китап бирүне дә яхшы оештыра.

2000 нче елда мин, Мусина Рафисә Рашид кызы китапханәдә эшлим. Иж-Бубый авыл китапханәсендә 2019 елның 1нче гыйнварендә 9718 данә китап бар. Шуларның 5608 - татар телендә, 4106 - рус телендә, 4-инглиз телендә.

Өлкәннәр, урта яшьтәгеләр һәм балаларга китап бирүне дәвам итәм. Эшемдә яңа алымнар кулланып  эшлим. Өлкәннәр китапханәгә бик яратып йөриләр. Балалар белән төрле кызыклы чаралар үткәрелеп барыла. Рәсәй, Татарстан, район күләмендә үткәрелгән  конкурсларда катнашам, яңалыклар эзлим.